| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ НАРАТЛЫ-КИЧУСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>НАРАТЛЫ-КИЧУ<br>АВЫЛ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге составына кергән Наратлы-Кичу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**17 ноябрь, 2019 ел.** **№1**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 10 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлегенең Наратлы-Кичу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

1. Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чаралырын тәэмин итү:
- мотопомпа сатып алу

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- ике телдә урам исемнәре һәм йорт нумерацияләре язылган алтакталар әзерләү.
-Мәгълүмат стендын әзерләү һәм урнаштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 203 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 106 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“Әйе” позициясе өчен 106 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

1. “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” мәсьәләсе буенча карарны танырга:

1. Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чаралырын тәэмин итү:

- мотопомпа сатып алу

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- ике телдә урам исемнәре һәм йорт нумерацияләре язылган алтакталар әзерләү.

--Мәгълүмат стендын әзерләү һәм урнаштыру.

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Наратлы Кичү авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ____________ Ф.Х. Минhажев

Наратлы Кичү авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе ______________ Ф.Х.Минhажев.